**ГЛАВА**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2022 № 3 Күләгәш авылы

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Байтуган торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. 2022 елның 29 октябрендә 12 сәгать 00 минутка, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Байтуган торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «2023 елда Күләгәш авыл җирлегенең Байтуган торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы затлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 300 сум күләмендә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, үзара салым чараларын кертүгә сез риза булырсызмы?»:

- янгын сүндерү машинасын тоту, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт шартнамәсе буенча түләү;

- үләнне чаптыру (хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

- халыкны су белән тәэмин итү (сууткәргеч торбалар сатып алу һәм алыштыру, хезмәт килешүе буенча түләү);

- Бөек Ватан сугышы елларында катнашучы якташлар хөрмәтенә куелган һәйкәлне агымдагы елда ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәт шартнамәсе буенча түләү).

«РИЗА» «Каршы».

3. Халык җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Байтуган авылы, Хезмәт урамы, 20нче йорт территориясе буенда үткәрергә.

4. Күләгәш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Ю.Н.ВАСИЛЬЕВ